**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«27» 06 2024 ел Яр Чаллы № 3018

2024 елның 01 июленнән Тукай районы халкы өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьясы, «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән вакытыннан артып киткән өзеклекләр белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында, торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2023 елның 14 декабрендәге 867 номерлы Указы, «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен

торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен кушымта нигезендә расларга.

2. «2023 елның 1 июленнән Тукай районы халкы өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2023 елның 30 июнендәге 2003 номерлы карары 2024 елның 1 июленнән үз көчен югалткан дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») район газетасында бастырырга.

4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27.06 3018 номерлы карарына кушымта

2024 елның 01 июленнән торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме һәм гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме

1 бүлек. Торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме

| № | Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) 2023 елның 01 июленнән |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 5,96 |
| 2. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,48 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру һәм чистарту | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,54 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 4,1 |
| 5. | Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,49 |
| 6. | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,33 |
| 7. | Дератизация (дезинсекция) | бер айга торак бинаның гомуми | 0,41 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мәйданы кв. м | |
| 8. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,90 |
| 9. | Йорт эчендәге газ җиһазларына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,27 |
| 10. | Төтенлекләргә хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,53 |
| 11. | Вентиляция каналларына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,48 |

2 бүлек. Муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен (наем өчен) түләү күләме

| № | Түләү исеме | Үлчәү берәмлеге | Наем өчен төп ставка (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | Наем өчен түләү | бер айга торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 7,7 |